**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел. 3-44-44, факс 3-44-14

КАРАР ________ ПГ-14 от 11.04.2025 ПОСТАНОВЛЕНИЕ №____

Актаныш муниципаль районы Башлыгының «Актаныш муниципаль районы вазыйфаи затлары мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү тәртибен раслау турында» 2017 елның 10 маендагы ПГ-13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 28 декабрендәге 547-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башлыгы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башлыгының «Актаныш муниципаль районы вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү тәртибен раслау турында» 2017 елның 10 маендагы ПГ-13 номерлы карарына (алга таба - Тәртип) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. Тәртипнең 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Гражданның мөрәҗәгате (алга таба - мөрәҗәгать) - дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) федераль дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба - Бердәм портал), дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының башка мәгълүмат системасын яки дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының рәсми сайтын гражданнарның идентификациясен һәм (яисә) аутентификациясен (әлеге Федераль закон белән башкасы билгеләнмәгән булса), тәкъдимне, гаризаны яисә шикаятьне, шулай ук гражданның дәүләт органына, җирле үзидарә органына телдән мөрәҗәгатен тәэмин итүче «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт органына яисә җирле үзидарә органына җибәрелгән мөрәҗәгатьләре;

1.2. Тәртипнең 6 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 6.3 өлеш өстәргә:

«6.3. Оператив-эзләү эшчәнлеген яисә Россия Федерациясенең иминлеген тәэмин итүне гамәлгә ашыручы органнарга, әлеге органнарның вазыйфаи затларына эчке эшләр өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының, федераль башкарма хакимиятнең иминлек тәэмин итү өлкәсендәге органының, тышкы разведка өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының, федераль башкарма хакимиятнең дәүләт саклау өлкәсендәге органының мөрәҗәгатьләренә бәйле рәвештә гражданнарның куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында электрон документ рәвешендә мөрәҗәгатьләр җибәрүнең һәм мөрәҗәгатьләргә җаваплар җибәрүнең махсус тәртибе билгеләнергә мөмкин.»

1.3. 7 бүлекнең 7.3 өлешендә «Бердәм портал» сүзләреннән соң «яисә дәүләт органының яисә җирле үзидарә органының гражданны идентификацияләүне һәм (яисә) аутентификацияләүне тәэмин итә торган башка мәгълүмат системасында»

сүзләрен өстәргә;

2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Район Башлыгы вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы И.Ш.Бариев